## Гимадиева Физа апа сөйли.

*(музей материалларыннан алынды.Ул 2016 елда безнең арадан китте)*

1941 нче елда туган. Урманасты Шынталы мәктәбендә башлангыч класс укытучысы булып эшләгән.

Моннан 15-20 еллар элек кенә дә башлангыч сыйныфларда укучылар түшләренә яшь Володя (Ленин) сурәте төшерелгән бишпочмаклы кызыл йолдызчык беркетеп октябрят, тагын берничә елдан өчпочмаклы кызыл галстук тагып пионер, өлкәнрәк сыйныфларда комсомол булып горурланып йөриләр иде әле. Хәер, без барыбыз да – бүгенге яшьләрнең әти-әниләре, әби-бабалары үз вакытында шушы әхлак, тәртип, туган илгә бирелгәнлек тәрбияләү мәктәбе аша уздык.

Мәктәптә һәрбер пионер отряды берәр шәхес исеме белән йөртелә иде.

Отряд тагын берничә звенога бүленә. Һәр звеноның кабат үз командиры бар.Звенода һәркемнең үз вазифасы: кемдер чисталык буенча җаваплы, кемдер өй эшләрен тикшерә,икенче берәү тимурчыларэше өчен җавап бирә, стена газетасычыгара һ.б.Звено җитәкчесе отряд командирына отчет-хисапбиреп бара, ай саен сбор, ягъни җыелыш үткәрелә, анда эшләгән эшләргә нәтиҗә ясала, тәртипсезләр "утлы табага" бастырыла. Отряд командиры исә үз чиратында хисапны дружина советы рәисенә биреп бара. Тәртип һәм контроль көчле! Хәзерге укучылар нәрсәгә буйсына?